ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.01.2020 № 14

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү Тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә түбәндәге айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә, ай саен 1 111 сум күләмендә укыту йөкләнеше күләменә, эшләнелгән вакытка пропорциональ рәвештә, әмма бер генә педагогик хезмәткәргә – яшь белгечкә дә 1 111 сумнан арттырмыйча өстәмә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү Тәртибен, әлеге карарга 1 нче кушымтада бәян ителгән нигезендә расларга.
3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү турында» 2019 елның 4 сентябрендәге 1344 карарын гамәлдән чыгарырга
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш һәм рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә алам.

Җитәкче Р. М. Нуриев

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 14 ” 17 01 ел 2020
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирүнең Алабуга муниципаль районы (алга таба - район) бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели.
2. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларда бирелә.
3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты - әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең баш бүлүчесе булып тора.
4. Айлык стимуллаштыру өстәмәсе билгеләнгән, педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә башка бюджетара трансфертлар бирелә.
5. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән тиешле финанс елына башка бюджетара трансфертлар күләмен бүлү раслана.
6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты агымдагы елның 1 февраленә кадәр Тармак министрлыкларына түбәндәге документларны тапшыра:

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган, муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык саен өстәмә түләүләр бирү Тәртибе;

расланган рәвештә башка бюджетара трансфертлар бирелүе турында гариза;

район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында, гаризаны имзалаган затның, вәкаләтләрен раслый торган документ;

Алабуга муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләр - яшь белгечләрнең расланган реестрлары;

муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыру өстәмәсен түләү өчен район бюджетында акча булуын раслаучы документ.

7. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Тармак министрлыклары арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар (алга таба - Килешү) турындагы килешү нигезендә бирелә башка бюджетара трансфертлар бирелә.
8. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты Тармак министрлыкларына хисап кварталыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында әлеге Тәртиптәге кушымта нигезендәге форма буенча хисап бирә.
9. Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кадәр кулланылмаган башка бюджетара трансфертларның калдыгын, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елга кире кайтарылырга тиеш.
10. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерда була һәм башка максатларда файдаланыла алмый.
11. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны законнар нигезендә гамәлгә ашыралар

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү Тәртибенә кушымта

Формасы

БАШКА БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ТУРЫНДА ХИСАП
ПЕДАГОГИКЛАРГА АЙЛЫК СТИМУЛЛАШТЫРУ ӨСТӘМӘЛӘРЕ
ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ-ЯШЬ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ

Муниципаль берәмлек ________________________________

| Функциональ чыгымнар статьясы коды | Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә саны, кеше | Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр түләүгә финансланган. | | | Өстәмә түләү чыгымнары (хисап чорында ел башыннан алып арта баручы нәтиҗә белән исәпләнгән акчалар күрсәтелә), сум. | | | Файдаланылмаган акча калдыгы, сум | | | Айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүнең уртача күләме (иминият кертемнәрен исәпкә алып) 6 графа/хисап чорында айлар саны - сум/ 2 графа |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән: | | барлыгы | шул исәптән: | | барлыгы | шул исәптән: | | |
| | | | айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру | дәүләт бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият взносларын түләү | | айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру | дәүләт тыш фондларга иминият взносларын түләү | | айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру | дәүләт тыш фондларга иминият взносларын түләү | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 0701 мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | | | | | | | | | | | |
| 0702 гомуми белем бирү оешмалары | | | | | | | | | | | |
| 0703 балаларга өстәмә белем бирү оешмалары | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | | | |

Җитәкче ____________________
Баш хисапчы ____________________
Башкаручы ____________________ телефон ____________